# ПӘЙГАМБӘРГӘ ДОГА КЫЛУ ҺӘМ САЛАВАТ ӘЙТҮ

**Г. ХӘЙРЕТДИНОВ** әзерләде

Гарәп телендә ул болай яңгырый: галәйһис-саләтү-вәссәләм. Гарәп телендә "Саләт" намаз дигәнне, шулай ук дорга дигән сүзне дә аңлатырга мөмкин. Монда шундый сорау туа: "Пәйгамбәр өчен ничек дога кылырга?".

Моның хакында Пәйгамбәребез (с.г.с.) үзе хәдисләрендә сөйләде.

Ибн Масуд җиткерә: "Без Сагд ибн Убадада утырганда, безнең янга Аллаһ илчесе килде. Бәшир ибн Сагд аңа болай диде: "Аллаһ безгә синең өчен дога кылырга кушты, ничек эшләргә аны?" Ул болай диде: "Әллаһүммә салли галә Мүхәммәдин вә галә әли Мүхәммәд, камә саләйтә галә Ибраһимә вә бәрик галә Мүхәммәд. Вә галә әли Мүхәммәд, камә бәрактә галә Ибраһимә". Ә сәлам бирә беләсез инде".

Габдрахман ибн Әбү ләйлә әйтә: "Миңа Кагб ибн Ужра очрады да болай диде: "Мин сиңа бүләк биримме? Без Пәйгамбәребездән: "Йә Аллаһ илчесе, без сине ничек сәламләргә кирәклеген белдек, ә синең өчен ничек дога кылырга?" - дип сорагач, ул (с.г.с.) салаватны укырга кушты.

Кайчан Пәйгамбәребез өчен дога кылырга кирәк,

1) Әттәхиятне укыгач. Пәйгамбәребездән түбәндәге хәдис килә: "Әгәр анда кыйраәт, әттәхият, салават укылмаса, ул намаз булып исәпләнми". Әлеге хәдисне Ибн Гомәр җиткерә. Аллаһ илчесе, шулай ук, әйтә: "Сезнең берәрегез дога кылса, башта Аллаһыны мактасын, аннары салават әйтсен, соңрак ни тели, шуны сорасын".

2) Җеназа намазында икенче тәкъбирдән соң.

3) Җомга һәм бәйрәм хотбәләре вакытында. Гали мөнбәргә менгәч, Аллаһны мактады, Пәйгамбәргә салават әйтте һәм: "Пәйгамбәрдән соң өммәттә иң яхшы кеше Әбү Бәкер, ә аннары Гомәр", - диде.

4) Азаннан соң. Аллаһ илчесе әйтә: "Мөәзиннең азан әйткәнен ишеткәч, сүзләрен кабатлап барыгыз, аннары минем өчен дога кылыгыз, кем минем өчен бер мәртәбә дога кыла. Аллаһ аңа 10 тапкыр күбрәк кайтара, аннары Аллаһтан минем өчен Вәсилне сорагыз, чөнки анда бер генә кеше керә ала, кем минем өчен шуны сорый, кыямәт көнне мин аңа шәфәгатьче булырмын".

5) Дога кылганда. Монда 3 дәрәҗә бар: Аллаһны искә алганнан соң, ихтыяҗларыгызны сораганчы, салават әйтергә; Пәйгамбәр өчен доганың башында, уртасында, ахырында салават әйтергә; Пәйгамбәребез өчен доганың башында һәм ахырында салават әйтергә кирәк. Гали: "Пәйгамбәргә салават әйтмичә, дога белән Аллаһ арасында киртә булачак, салават әйткәч, киртә юкка чыга, догасы да кабул булыр. Тәһарәт намазның ачкычы булган кебек, салават доганың ачкычы булып тора".

6) Мәчеткә кергәндә һәм аннан чыкканда. Аллаһ илчесе әйтә: "Кем мәчеткә керә, шул Пәйгамбәрне сәламләр һәм әйтер: "Аллахумма фтахли абваба рахматик", чыкканда да сәламләсен һәм болай дип әйтсен: "Аллахумма адҗирни минашшайтаннирраджим".

7) Сафа һәм Мәрва тауларында. Гомәр ибн әл-Хаттаб болай диде: "Кем хаҗ кылырга тели, шул 7 мәртәбә таваф кылсын, аннары Ибраһим макамы янында 2 рәкәгать укысын, аннары кара ташны сәламләсен, 7 тәкъбир әйтсен, һәрберсеннән соң Аллаһы мактасын, аннары салават әйтсен, аннары үзе өчен дога кылсын, Мәрва тавында да шуны ук эшләсен".

8) Мәҗлесләр һәм очрашулар вакытында. Аллаһ илчесе әйтә: "Әгәр мәҗлестә Аллаһ искә алынмаса, салават әйтелмәсә, шуларга бу мәкрүһ була, Аллаһ теләсә, ярлыкый, теләсә, җәзалый".

9) Пәйгамбәрне искә алганда. Мөхәммәд пәйгамбәр әйтә: "Әгәр мине искә алсалар, салават әйтегез, кем бер тапкыр салават әйтә, Аллаһ аңа 10 тапкыр бәрәкәт бирә". Икенче хәдистә болай дилә: "Кем миңа салават әйтми, шул саран".

10) Иртән һәм кичен. Аллаһ илчесе әйтә: "Кем яктыда һәм караңгыда миңа 10 салават әйтә, Кыямәт көнне мин аңа шәфәгать итәрмен".

11) Аллаһ илчесенең каберенә баргач. Габдулла ибн Динар Пәйгамбәребезнең кабере янында Габдулла ибн Гомәрнең салават әйткәнен күрә.

12) Базарга яки динне аңлатырга барганда. Күп кеше җыелган җирдә Аллаһны мактаганнан соң Пәйгамбәргә салават әйтәсең.

13) Бәйрәм намазларында. Ураза, Корбан бәйрәмнәрендә һәм җомга көнне Аллаһ илчесе дә искә алынырга тиеш.

14) Җомга көн көндезләрен һәм кичләрен. Пәйгамбәребез (с.г.с.) әйтә: "Җомга көн көндезләрен һәм кичләрен миңа күбрәк салаватлар әйтегез, кем бер салават әйтә, шуңа Аллаһ 10 бәрәкәт бирә".

15) Коръәнне тулысынча укып чыккач. Мәлик ибн Әнәс Коръәнне тулысынча укып чыккач, бөтен гаиләсен чакырган. Андый мәҗлесләрдә Аллаһ илчесен дә телгә алырга кирәк.

16) Укыганда. Габбас әл-Әнбари әйтә: "Хәдис ишеткән саен салават әйтә идек".

17) Авырлык килгәндә. Бер кешегә авырлык килгәч, бөтен догасын Пәйгамбәргә салават әйтүгә багышлый, соңрак аның кыенлыклары да бетә, гөнаһлары да ярлыкана.

18) Теләсә-кайда салават әйтү. Бу Пәйгамбәребезгә булган мәхәббәтне арттыра, ләкин ул телдә генә калырга тиеш түгел, ә мөселман бәндәсенең тормышында да чагылырга тиеш. Аллаһка мактау, ә Пәйгамбәребезгә салават-шәрифләребез хас.

## Кытайда Коръән музее төзеләчәк

Кытайның үзәк өлешенең төньягында урнашкан (биредә мөселманнар күпләп яши) Ганьсу провинциясенең Линься-Хуэйск автоном округы власте Коръән музее төзү өчен дүрт миллион юань (якынча 636000 АКШ доллары) күләмендә акча бүлеп бирергә дигән карарга килгән.

Монда изге Коръәннең гарәп телендә язылган иң сирәк һәм борынгы (мең елдан артык "яшәгән" китаплар) экземплярлары сакланачак.

Кытай телевидениесеннән хөкүмәт вәкиле белдергәнчә, "Бүлеп бирелгән акчаларга күргәзмә залларын, видеокүзәтүләрне тәшкил иткән 800 квадрат метрлы музей төзеләчәк, биредә Коръәннең иң борынгы экземплярларын саклау өчен алдынгы технологияләр файдаланылачак". Чиновник шунысын да искәртте: төзелеш быел апрель аенда башланды, аны ел ахырына тәмамлау күздә тотыла.

Шунысын да искәртеп узарга кирәк: Коръәннең Сәмәрканд кәгазеннән эшләнгән (Үзбәкстан) гарәп телендәге 536 битлек борынгы кульъязмасы узган елны Ганьсу провинциясендә табылган иде. Кытай, Бөекбритания һәм Япония белгечләре фикеренә караганда, кульъязмалар IX һәм XI гасыр араларында язылган һәм ул Кытыйда Коръәннең иң борынгы кульъязмасы булып санала.

## Рәхмәт хаты

Без, икенче курсны тәмамлаучы шәкертләр, үзебезнең зур рәхмәтебезне мәдрәсә җитәкчеләренә - Илдар һәм Ильяс хәзрәткә белдерәсебез килә. Шушы мәдрәсәдә эшләүче Рәфис һәм Илһам хәзрәтләргә, Аль-Әзһәр университетыннан килеп, безгә белем бирүче шейхлар: Абдразак, Мөхәммәдгалин, Гарабига да иң ихлас теләкләребезне җиткерәбез. Аларга нинди генә сорау, үтенеч белән мөрәҗәгать итсәк тә, һәр вакытта безгә ярдәмгә киләләр. Шулай ук аерым рәхмәтләрне II курс шәкерте Рәхмәтуллага да әйтәбез. яшь кенә булуына карамастан, ул бик тә зур белемгә ия, шейхлар белән аралашуда ярдәм итеп торды.

Югарыда телгә алынган хәзрәтләребезнең барсына да Ходай исәнлек, гаилә именлеге бирсен, балалар игелеге күрергә насыйп әйләсен. Барлык укучы шәкертләр исеменнән, староста Йосып Исмаев.

## 2012 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

**(Мөселман ай календаре буенча 1433-1434 һиҗри еллар)**

**24 октябрь** - Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**25 октябрь** - Гайдел-Әдъхә, ягъни Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә.

**26, 27, 28 октябрь** - Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**15 ноябрь** - 1434 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**24 ноябрь** - Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлиәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

***Төзүче*** **Абдулла хаҗи ДУБИН.**

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Зөлҡәғиҙә 2012 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Зөлкағиҙә | Аҙна көндәре | Сентябрь Октябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығa | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дүшәмбе | 17 | 6.24 | 7.54 | 14.30 | 18.55 | 20.25 | 21.55 |
| 2 | Шишәмбе | 18 | 6.26 | 7.56 | 14.30 | 18.53 | 20.23 | 21.53 |
| 3 | Шаршамбы | 19 | 6.28 | 7.58 | 14.30 | 18.50 | 20.20 | 21.50 |
| 4 | Кесе йома | 20 | 6.30 | 8.00 | 14.30 | 18.47 | 20.17 | 21.47 |
| 5 | Йома | 21 | 6.32 | 8.02 | 14.30 | 18.45 | 20.15 | 21.45 |
| 6 | Шәмбе | 22 | 6.33 | 8.03 | 14.30 | 18.42 | 20.12 | 21.42 |
| 7 | Йәкшәмбе | 23 | 6.35 | 8.05 | 14.30 | 18.40 | 20.10 | 21.40 |
| 8 | Дүшәмбе | 24 | 6.37 | 8.07 | 14.30 | 18.37 | 20.07 | 21.37 |
| 9 | Шишәмбе | 25 | 6.39 | 8.09 | 14.30 | 18.35 | 20.05 | 21.35 |
| 10 | Шаршамбы | 26 | 6.41 | 8.11 | 14.30 | 18.32 | 20.02 | 21.32 |
| 11 | Кесе йома | 27 | 6.43 | 8.13 | 14.30 | 18.30 | 20.00 | 21.30 |
| 12 | Йома | 28 | 6.45 | 8.15 | 14.30 | 18.27 | 19.57 | 21.27 |
| 13 | Шәмбе | 29 | 6.47 | 8.17 | 14.30 | 18.25 | 19.55 | 21.25 |
| 14 | Йәкшәмбе | 30 | 6.48 | 8.18 | 14.30 | 18.22 | 19.52 | 21.22 |
| 15 | Дүшәмбе | 1 | 6.50 | 8.20 | 14.30 | 18.19 | 19.49 | 21.19 |
| 16 | Шишәмбе | 2 | 6.52 | 8.22 | 14.30 | 18.17 | 19.47 | 21.17 |
| 17 | Шаршамбы | 3 | 6.54 | 8.24 | 14.30 | 18.14 | 19.44 | 21.14 |
| 18 | Кесе йома | 4 | 6.56 | 8.26 | 14.30 | 18.12 | 19.42 | 21.12 |
| 19 | Йома | 5 | 6.58 | 8.28 | 14.30 | 18.09 | 19.39 | 21.09 |
| 20 | Шәмбе | 6 | 7.00 | 8.30 | 14.30 | 18.07 | 19.37 | 21.07 |
| 21 | Йәкшәмбе | 7 | 7.02 | 8.32 | 14.30 | 18.04 | 19.34 | 21.04 |
| 22 | Дүшәмбе | 8 | 7.04 | 8.34 | 14.30 | 18.02 | 19.32 | 21.02 |
| 23 | Шишәмбе | 9 | 7.06 | 8.36 | 14.30 | 18.00 | 19.30 | 21.00 |
| 24 | Шаршамбы | 10 | 7.07 | 8.37 | 14.30 | 17.57 | 19.27 | 20.57 |
| 25 | Кесе йома | 11 | 7.09 | 8.39 | 14.30 | 17.55 | 19.25 | 20.55 |
| 26 | Йома | 12 | 7.11 | 8.41 | 14.30 | 17.52 | 19.22 | 20.52 |
| 27 | Шәмбе | 13 | 7.13 | 8.43 | 14.30 | 17.50 | 19.20 | 20.50 |
| 28 | Йәкшәмбе | 14 | 7.15 | 8.45 | 14.30 | 17.47 | 19.17 | 20.47 |
| 29 | Дүшәмбе | 15 | 7.17 | 8.47 | 14.30 | 17.45 | 19.15 | 20.45 |
| 1 | Шишәмбе | 16 | 7.19 | 8.49 | 14.30 | 17.43 | 19.13 | 20.43 |

**Кыйсса**

# Сабыр иткән - морадына җиткән



Сөләйман пәйгамбәр заманында гарәпләрдән берәү, бер сандугачның авазына гашыйк булып, сайратыр өчен аны сатып алды. Бу сандугач гарәп кулында берничә көннәр сайрады. Аннары сайрамас булды. Гарәп әлеге кошны Сөләйман пәйгамбәр янына алып барды, чөнки ул кошлар телен белә иде.

Гарәп әйтте:

- Бу кошны сайратыр өчен алган идем, берничә көннәр сайрады да тынып калды. Ни сәбәптән тынып калды икән? - диде. Сөләйман пәйгамбәрдән үтенде: - Сандугачтан сора әле, - диде.

Сөләйман сандугачтан сорады:

- Ни өчен тынып калдың?

Кош Сөләйман пәйгамбәргә әйтте:

- Баштагы сайравым шуның өчен: сөйгәнемне искә алып елар идем. Инде һавадан кошлар очып килеп, мине тәрәзәдән сөйгәнем күрде, миңа күп нәсыйхәтләр әйтте: "Бу кадәр елама, Алла теләсә, бер кавышырбыз", - диде. Шуннан соң тынычланып калдым, - диде.

Сөләйман пәйгамбәр сандугачның сүзен иясенә белдерде. Сөләйман пәйгамбәр кошны сатып алырга теләде, иясе сатты. Сөләйман сандугачны алганнан соң, азат итеп, очыртып җибәрде.

* * *

Бу хикәяттән гыйбрәт мәгълүм булды: һәртөрле авырлыкларда сабырлык иң яхшысыдыр.

### АКЫЛ нәрсә дә, гыйлем нәрсә

Бер кешенең бер тилемсә углы бар иде. Ул углын йолдызлар гыйлемен өйрәтүче остазга - мөнәҗимгә бирде. Әйтте:

- Әй остаз! Син минем углымны йолдызлар гыйлеменә шулкадәр өйрәт ки, ул гыйлемнән синең кадәр белсен, - диде.

Аннан соң ул остаз аның углын алып калды. Бөтен иҗтиһадын, тырышлыгын биреп өйрәтте ки, бу тиле малай аның үзе кадәр белүче булды. Шулай өйрәнеп җиткәч, остаз аны өенә кайтарды.

Атасы, үзенең кулындагы йөзекне учына йомарлап, углына әйтте:

- Әй углым, бу нәрсә? Әгәр йолдызлар гыйлеменнән хәбәрең булса әйт, - диде.

Малае бераз карап, уйланып торгач, әйтте:

- Бер түгәрәк нәрсә, үзе таш, - дип.

Моны ишеткәч, атасы шатланды һәм тагын сорады:

- Ни сыйфатлы? - дип.

Углы әйтте:

- Уртасы тишекле.

Моны ишеткәч атасы тагын да шатланды, белә икән, дип уйлады һәм тагын сорады:

- Исеме ничек соң?

Углы җавап бирде:

- Тегермән ташы! - дип.

Моны ишетеп, атасы ни эшләргә дә белмәде, бик кайгырды.

* * *

Инде сүз ахырында моннан гыйбрәт булыр: кайбер кешедә акыл камил, җитешле булыр, ләкин гыйлеме булмас. Ә кайбер кешедә гыйлем булса да, акыл булмас.

Күрдегез ки, бу углан да гыйлем куәте белән әйбернең ни рәвешле икәнен белде, әмма акылы юклыктан, тегермән ташының учка сыймаганын белмәде.

Шуңа күрә әйткәннәр: гыйлем башка да, акыл башка.